**III ЧАКЫРЫЛЫШ**
**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БӨГЕЛМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**УТЫЗ СИГЕЗЕНЧЕ СЕССИЯ**

**КАРАР № 5**

Ключи авылы «20» май 2019 ел

**«Татарстан Республикасы**
**Бөгелмә муниципаль районы**
**«Ключи авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлегендә муниципаль**
**хезмәт турындагы Нигезләмә турында»**
**2017 елның 4 июлендә кабул ителгән**
**Ключи авыл җирлеге Советының**
**XVIII сессиясенең 2нче карарына**
**үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 30 октябрендә кабул ителгән №382-ФЗ, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнарын оештыруның һәм аларның эшчәнлегенең гомуми принциплары турында» Федераль законның 7 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендә кабул ителгән №559-ФЗ һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль законның 13 маддәсенә таянып, шулай ук муниципаль хезмәт турында 2013 елның 25 июнендә кабул ителгән №50-ТРЗ Татарстан Республикасы Кодексы нигезендә

**Ключи авыл җирлеге Советы**

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Ключи авыл җирлеге Советының 2017 елның 4 июлендә булып узган XVIII сессиясендә кабул ителгән «Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районы «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә турында»гы 1нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

*1.1. 13 маддәне яңа 4 һәм 5 өлешләр белән тулыландырырга:*

«4. «Ключи авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башлыгы (башкарма комитет җитәкчесе) белән якын туганлык яисә үзлекләр мөнәсәбәтендә (атасы-анасы, хатыны, балалары, бертуганнар, сеңелләре, абыйлары шулай ук, иренең яки хатынының ата-анасы, бертуганнары, сеңелләре, балалары) булганда,

гражданин муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына, ә муниципаль хезмәткәр муниципаль берәмлекнең тикшерү-хисап органы рәисе, рәис урынбасары һәм аудиторы вазыйфасына билгеләнә алмый.

5. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр әлеге вазыйфаны биләгән чорда җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, әлеге җирле үзидарә органының сайлап куела торган профсоюз органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләрен яклый алмый.».

2. Әлеге карарны җирлек территориясендәге мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм «Интернет» челтәрендә – Бөгелмә муниципаль районының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.

**«Ключи авыл җирлеге»**
**муниципаль берәмлеге башлыгы** **В.А. Батаев**